ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 28 июне** **Чистай шәһәре** **№ 357**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 февралендәге 93 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 3 июнендәге 1053-р номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 13 ноябрендәге 2445-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2021 елга республика бюджеты акчаларыннан финанслау» 2 нче кушымтасына 5, 6 нчы юллар өстәргә;

1.2. «2021 елга җирле бюджет акчаларыннан финанслау» 3 нче кушымтасын кушымта нигезендә өстәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов